ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЧИРМЕШӘН АВЫЛЫ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

# КАРАР

13 май, 2019 ел №123

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы "Чирмешән авыл җирлеге" муниципаль берлегенең җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Чирмешән авыл җирлеге Советы карар итте**:**

1. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Чирмешән авыл җирлеге Советының 2014 елның 8 августыннан 51 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы «Чирмешән авыл җирлеге» муниципаль берлегенең җирдән куллану һәм төзелешләр кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

36 статьяның 5 бүлегендәге 1 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Торба үткәргечләрне зарарлау мөмкинлеген бетерү өчен сак зоналары билгеләнә. Торба үткәргечләрнең сак зонасы күләме магистраль торба үткәргечләрне саклау кагыйдәләре белән билгеләнә (Россия Федераль Тау һәм сәнәгать күзәтчелегенең 1992 елның 24 апрелендәге 9 номерлы карары белән расланган).».

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының рәсми сайтында җирлек бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Бакырчы авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Чирмешән авыл
җирлеге башлыгы А.Т.Зиннатуллин